УДК 908

# РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЭШЛӘРЕНДӘ МӨҺИМ ТАРИХИ ЧЫГАНАК БУЛАРАК МЕТРИКА КЕНӘГӘЛӘРЕ

***Э.К. Сәлахова***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*ilsalah@mail.ru*

Метрика кенәләре – тарихи тикшеренүләр өчен кыйммәтле материал бирә ала торган мөһим чыганаклар комплексының берсе. Кызганычка каршы, тарихи хезмәтләрдә метрика кенәгәләрен тарихи чыганак буларак куллану дәрәҗәсе хәзерге көннәргә кадәр түбән булып кала бирә. XX гасыр башында Р. Фәхреддин чыганакларның бу комплексына игътибар итә, ул аларны үзенең тарихи тикшеренүләрендә кулланып кына калмыйча, аларны саклауга да зур өлеш кертә. Мөселман метрика кенәгәләренең зур фонды сакланып калган икән, бу, һичшиксез, СССР мөфтие Р. Фәхреддиннең казанышы.

Р. Фәхреддиннең атаклы хезмәтләре *«Мәшһүр ирләр»*, *«Мәшһүр хатыннар»*, *«Асар»*ның төп чыганаклары булып метрика кенәгәләре тора. *«Асар»* хезмәтен аерым билгеләп үти кирәк, анда метрика кенәгәләре материаллары нигезендә Р. Фәхреддин атаклы шәхесләрнең, галимнәрнең, имамнарның тәрҗемәи хәлен, аларның туу, вафат булу даталарын, шәҗәрәләрен төгәл ачыклауга ирешә.

Мәкалә авторының максаты – Р. Фәхреддиннең фәнни тикшеренү хезмәтләрендә метрика кенәгәләренең урынын һәм аларның мөһимлеген күрсәтү. Куелган максатка ирешү өчен берничә бурыч куелды, алар: тарихи чыганаклар буларак метрика кенәгәләре турында аналитик материал бирелү, Р. Фәхреддиннең үз хезмәтләрендә метрика кенәгәләрен куллану дәрәҗәсе, шулай ук тулы бер фәнни темаларны ачуда метрика кенәләренең чыганакчыл мөмкинлеге күрсәтелә. Тәкъдим ителгән мәкаләдә Р. Фәхреддиннең фәнни мирасы мондый ракурста беренче тапкыр карала. Р. Фәхреддиннең үз кулы белән язылган тәрҗемәи хәлендә метрика кенәгәләреннән күчермәләрнең күп булуына автор игътибарны юнәлтә.

Автор соңгы вакытта актуальләшеп киткән дискуссион моментларга игътибарны юнәлтә, алар – метрика кенәгәләрендә теркәлгән кешеләрнең кайсы милләткә каравы. Мәкалә авторы тикшеренүләре буенча метрика кенәгәләрендә күрсәтелгән кешенең социаль статусы аның милләте буларак кабул ителә алмый. Автор инануы буенча, метрика кенәгәләрен тутыру кагыйдәләре буенча аларда кешенең милләте язылу күздә тотылмаган, моннан кала бу төр документларда кешенең милләте бернинди роль уйнамаган.

Р. Фәхреддин – чыганаклар белән эшләгән галим, аның метрика кенәгәләренә мөрәҗәгать итүе, аларга ихтирамлы мөнәсәбәте бу чыганакларның татар язма чыганаклар комплексындагы мөһимлеген раслый. Метрика кенәгәләренең күләмле комплексын мөһим тарихи чыганак буларак өйрәнү тарих фәнендә мөһим фәнни тикшерү юнәлеше булырга тиеш.

*Сәлахова Э.К.* Ризаэддин Фәхреддиннең фәнни-тикшеренү эшләрендә мөһим тарихи чыганак буларак метрика кенәгәләре

**Төп төшенчәләр:** Ризаэддин Фәхреддин, метрика кенәгәләре, татар тарихи чыганаклары, архив документлары, мөселманнарның Диния нәзарәте, Р. Фәхреддиннең фәнни мирасы, татар галимнәре, татар тарихы, XX йөз башы

**Сылтама ясау өчен:** Салахова Э.К. Ризаэддин Фәхреддиннең фәнни-тикшеренү эшләрендә мөһим тарихи чыганак буларак метрика кенәгәләре // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 318–330. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.318-330

Ризаэддин Фәхреддин киңкырлы галим, ул тарихчы, талантлы журналист, педагог-мәгърифәтче, язучы, күренекле дин әһеле, фикер иясе буларак билгеле. Аның эшчәнлегенең һәр тармагы аерым зур тикшерүләргә мохтаҗ. Аның мирасының зур өлеше, кызганычка каршы, әлегә кадәр тулысынча тикшерелмәгән. Бик күп хезмәтләре әлегә кадәр кульязма хәлендә кала бирә. Шулар арасында, тарихи проблемаларга багышланган хезмәтләрнең күпсанлы булуын да күрсәтергә кирәк. Р. Фәхреддиннең мирасына карасак, ул татар тарихи әдәбиятына биоблиографик хезмәтләр алып килгән галим. Үзе җитәкләгән *«Шура»* журналындагы һәр санда диярлек билгеле аерым шәхесләргә багышланган биоблиографик характердагы язмалары басылып барган. *«Мәшһүр ирләр»*, *«Мәшһүр хатыннар»* хезмәтләрендә төрле халык вәкилләре булган тарихта эзле бөек кешеләр турында биографик мәгълүмат тупланган. Бу юнәлештәге иң мәшһүр хезмәте, әлбәттә дүрт томлык *«Асар»* хезмәте (Фәхреддин 2006: 360). Һәр кеше хакында тәфсилле материал бирү, зур чыганак базасы белән таныш булу, аның белән оста эш итүне таләп итә торган хезмәт. Бу хезмәткә кергән фактлар төрле чыганаклардан бөртекләп җыелган материаллар. Р. Фәхреддиннең *«Асар»* дип аталган күләмле мөһим хезмәтен өйрәнгән тарихчы Л. Байбулатова күрсәтүенчә, галим *«Асар»* хезмәтен язуга кулланган документаль чыганаклар күптөрле: алар арасында эш документлары (Диния нәзарәтенең эшчәнлеге белән бәйле документлар), статистик материаллар (ревизия документлары, метрика кенәгәләре), эпиграфик, фотодокументаль һәм башка чыганаклар (Байбулатова 2004: 22).

1788 елның 22 сентябрендә Екатерина II Указы белән булдырылган мөселманнарның Диния нәзарәте дәүләт белән мөселман дөньясы арасында бер арадашчы да, контроль органы да була (Азаматов 1996: 20). Диния нәзарәте Россия мөселманнары тормышында булган вакыйгаларны, андагы халәтне чагылдырган документларны туплаган оешмага рәвешен ала. Озак вакыт яшәп-эшләп килгән бу оешма документлары Диния нәзарәтенә казый булып килгән тарихчы-галим Р. Фәхреддин өчен зур байлыкка, галим өчен зур табышка әйләнә, хәтта бу вакыт аның тормышында борылыш чоры була дип тә әйтә алабыз. Риза казыйга нәзарәттә йөз ел дәвамында барлыкка килгән бай архивны җентекләп өйрәнү, тәртипкә салу да насыйп була. Р. Фәхреддин рәсми документларны фәнни

хезмәтләрендә тарихи чыганак буларак актив кулланучы беренче татар галиме. Диния нәзарәтенең төрле мәхәлләләр, чиновниклар белән язышу кәгазьләре, бәхәсле хәлләрне чишү буенча булган документлар, хосусый хатлар, әлбәттә инде Россиянең һәр мөселман мәхәлләсеннән озак еллар буе җыелып барган метрика язмалары аның биоблиографик хезмәтләренең нигезенә ята.

Метрика язмалары уникаль тарихи чыганаклар. Тарихи чыганак буларак бу документларның фәнни тикшеренүләргә әле дә тиешле дәрәҗәдә керә алганы юк. Хәзерге вакытта да фәнни эшләрендә бу чыганакны кулланучы берничә тикшерүчене генә атый алабыз. Чыганакларның кыйммәтен һәм әһәмиятен белгән Риза казый бу чыганакларның мөһимлеген күргән, аларны үз хезмәтендә кулланган иң беренче галим.

Метрика язмалары – гражданлык халәтен теркәгән документлар. Россия империясендә метрика кенәгәләре дигән документларны алып бару барлык диндәгеләр өчен дә тиеш булган. Аларның гамәлгә куелуы гына төрле диннәр өчен төрле вакытка туры килә. Православиядәге халыкны метрика кенәгәләренә терки башлау 1722 елдан башлана, ә Мәскәү халкының туу, җирләүне теркәү 1702 елда ук башланган була. Католиклар өчен бу 1826 елда, ә мөселманнар өчен 1828 елда гамәлгә керә, лютеран чиркәве өчен бераз соңрак – 1832 ел, яһүдиләр өчен 1835 ел, раскольникларда 1874 ел. Сенатның 1828 елның 21 сентябрь Указы «О введении в употребление метрических книг по Оренбургскому духовному магометанскому управлению» Оренбург Диния назарәтенә һәм Таврия мөфтиятенә караган барлык губерналар өчен дә тарала. Православия метрика язмаларыннан аермалы буларак мөселман метрика язмалары өч сәхифәдән торган, анда талак, ягъни аерылышу фактларны да теркәлгән. Шушы указ нигезендә мәхәллә метрика кенәгәсен, формулярны ике экземплярда алган. Күчермәсе мәхәлләдә калган, ә төп нөсхә киләсе елның февраленнән дә калмыйча нәзарәткә җибәрелгән. Беренче вакытта метрика алу, аны җибәрү, алып бару расходлары 700 сум күләмендә дәүләт казнасыннан капланган булса, алга таба бу расходлар тулысы белән мәхәллә өстенә кала (Усманова 2004: 40–53). Шулай итеп, Диния нәзарәте үзенә күрә бер нотариаль контора статусын да ала.

1918 елны гражданлык халәте хакындагы Декрет чыкканнан соң метрика алып бару инде руханилар вәкаләтендә булмый, ул инде дәүләткә күчә һәм ул ЗАГС дип атала башлый. Әмма, шулай булса да, бу вакыттагы сәяси халәт, гражданнар сугышы бу Декретның чын мәгънәсендә гамәлгә керүен тоткарлый. Кайбер мәхәллә имамнары 1930 елларга кадәр традицияне дәвам итеп, метрика тутыру эшен алып барганнар. Бу чор метрика язмалары юридик көчкә ия булмаса да, тарихи чыганак буларак гаять мөһим һәм уникаль чыганаклар булып тора. Бу болганчык еллардан сакланып калган документлар күп түгел, шуңа күрә дә бу чорны күзаллауда, формаль яктан караганда рәсми документ булып саналмаса да, метрика язмаларының материаллары тарихи яктан кыйммәтле.

Димәк ки, Указ кабул ителгәннән соң, 1829 елдан башлап 1918 елга кадәр генә вакытны алсак та, Россия империясендәге һәр мөселман мәхәлләсендә метрика кенәгәсенең ике экземплярда тутырылуын исәпләсәк, бу чыганаклар күпсанлы чыганаклар, тарихи чыганакларның зур массасын тәшкил иткәнен күрергә була. Метрика кенәгәләренең беренчел экземплярлары киләсе елның февраленнән дә калмыйча Диния нәзарәтенә җибәрелгән, ә икенче экземпляр мәчетнең үзендә сакланган. Һәр елны һәр мәхәлләдән килгән документлар Диния нәзарәтенең документациясенең иң зур өлешен тәшкил иткән, шунда тупланып барган. Монда җыелган метрика кенәгәләренең саны шулкадәр күп була ки, аларны тәртипкә китерү, системага салу һәм кулланырлык итү үзе бер зур проблемага әйләнә. Төрле сорауларга җавап бирү, белешмәлек тутыру өчен бу документларга мөрәҗәгать итү еш булса да, Диния нәзарәтендә моның белән шөгыльләнүче махсус кеше булмый. Ризаэддин Фәхреддин нәзаратькә эшкә килгәч, мондагы хәлләрне күреп үз тәрҗемәи хәлендә «нәзарәтнең эшләре дә гаять буталчык рәвештә оештырылуын күрдем», дип яза (Фәхреддин 1999: 37).

> «Метрикәләрне тәмам тырышлык илә матур иттереп бастырдым. Архивны тәртипкә салырга тырыштым, хәтта үз күзәтчелегем илә күп вакыт өстендә торып киңәш бирер идем. Менә боларны үзем язмаган булсам, мине иң якын күргән кешеләр дә язмаслар иде. Бу эшләр, аеруча, архив хезмәтләре минем өстемә махсус бер хезмәт түгел иде. Мин фәкать үз теләгем илә боларны башкардым. Архивның тәртипле булуының файдасын хәтта Мәхкәмәдә туып-үскән адәмнәрнең дә беркадәресе белмәсләр. Моның ни дәрәҗәдә мөһим бер нәрсә икәнлеген аңлаучылар тәкъдир итәр дип уйласам, андыйлар да һәр гасырда, кулдагы бармаклар санынча, күп булмаслар», дип яза (Фәхреддин 1999: 37).

Метрика кенәгәләренең иң зур, иң бай коллекциясе Башкортостан милли архивында саклана дибез икән (Кутушев 2012: 54–59), бу документларны архивның зур фонды итүдә, аны тәртипкә салуда, Россиядә булган авыр вакытларда, гражданнар сугышы барган елларда күп документлар юкка чыккан чорда сакланып калган икән, бу, һичшиксез, беренче чиратта Ризаэддин Фәхреддиннең зур хезмәте. Бу гына да түгел, ул килгәндә идәндә тузып яткан документларны саклау өчен Диния назарәтенең ишегалдында таш бина салдырыртып, хәзерге архивларга да үрнәк була алырлык тәртип белән документларны урнаштыра. 1922–1935 еллар аралыгында шул документларны саклап калу тырышлыгы белән бик күп кешеләргә мөрәҗагать итә, үтенеч хатлары яза. Диния нәзаратенең архивы галим Ризаддин Фәхреддин өчен иң яраткан, көннәрен шунда уздыра торган урын була, хәтта ул ял вакытларын да бирәдә уздырган. Үз ризалыгыннан тыш мөфтилеккә сайлангач та, ул бу вазыйфага килгәндә, тарихи язмаларга килүе, архивта эшләп гыйльми хезмәт белән шөгыльләнергә мөмкинлек булуы белән үзен юата. «Андагы тарихи язмаларны,

метрикаларны эшләп, үзенә кирәк даталарны тикшереп, актарынып үткәргән сәгатьләре бик еш була иде», дип яза истәлекләрендә кызы Әсма Шәрәф (Фәхреддин 1999: 39–80).

Р. Фәхреддин үз хезмәтләрендә метрика язмаларын ни дәрәҗәдә куллануы, аның бу тарихи чыганакларга булган мөнәсәбәтен аның үз сүзләре белән аңлату иң дөресе булыр. Ул болай яза:

> «Әгәр берәр кеше читтән тикшереп торса, Риза казый архивта нинди байлыклар эзли икән? Берәр хәзинә бардыр, шуны табарга маташа торгандыр, дип уйлыйлардыр. Хәлбүки, 3–4 сәгать вакыт сарыф итеп, тузанга батып, актарынып *"Асар"*га языла торган 3–4 кешенең дөрес туган-үлгән елларын табу минем өчен бер чиләк алтыннан кыйммәтле була» (Фәхреддин 1999: 8–38).

Ризаэддин Фәхреддиннең әлеге сүзләре аның ни дәрәҗәдә җентекле, һәр фактның зур кыйммәтен аңлый торган тикшерүче-галим булуын күрсәтә торган дәлил. Аның күптомлы тарихи кыйммәте ягыннан бик көчле, әһәмиятле, энциклопедистик хезмәте *«Асар»*ның нигезендә тарихи чыганаклар – метрика кенәгәләре ята. Тарихта эзле булган һәр шәхес турында язганда һәр язмасында бу кешенең туу, вафаты турында мәгълүмат төгәл көне белән күрсәтелә, бу төгәллекне, әлбәттә метрика язмалары гына бирә ала. Метрика язмалары нигезендә ул шәхесләрнең гаиләсе: никахлы хатыны, балалары, аның нәсел-нәсәбе турында да яза. Бу төгәллекне булдырган *«Асар»* киләчәктә тарихны өйрәнү өчен, тарихи очерклар өчен, гомумән, татар тарихы өчен тиңе булмаган чыганак. Фактик материалларга бай булган биоблиографик *«Асар»*ның ни дәрәҗәдә мөһимлеге һәм аның алыштыргысыз хезмәт булуы үз заманыннан да бигрәк, хәзерге буын өчен кадерле. Р. Фәхреддин хезмәте тарихта эзле шәхесләрнең тәфсилле энциклопедиясе (Фәхреддин 2006: 360). Бу хезмәтнең мәгълүмати байлыгы, бигрәк тә, аерым төбәк тарихын өйрәнү өчен төп чыганакларның берсе, чөнки шул төбәкнең имам-мулласы, аның рухи юлбашчылары хакында, аларның нәсел-нәсәбе белән теркәгән башка хезмәтләр юк. Төбәкнең рухи тормышын өйрәнүдә *«Асар»* күп кенә очракта бердән-бер тарихи чыганак икәнен танырга кирәк. Кызганычка каршы, рәсми архив документлары мондый төгәллекне бу дәрәҗәдә җыеп бирми, ә башка язмалар, мулла, имам язмалары төрле сәбәпләр аркасында бүгенге көнгә кадәр сакланып калмаган. Хәтта ки, *«Асар»* рәсми архив документларында бирелгән даталарның ялгышлыгын да күрсәтә, төгәллек кертә. Үз тәрҗемәи хәлен язган вакытта да Ризаэддин Фәхреддин һәр фактны метрика язмасында язылган рәвешендә төгәллек белән яза. Бу – аның гыйльми эзләнүче булу гадәте, тарихчы-тикшерүче гомуми сүзләр белән сөйли алмый, аңа, беренче карашка, вак әйбер булып тоелган нәрсә дә, тарих өчен мөһим факт. Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләрендә метрика язмаларының материаллары тулы бер нәсел тарихын торгызу, татар тарихының рухи тормыш халәтен, үсешен билгеләүче имам, мулла, мөдәррисләр нәселен, аларның тәрҗемәи хәлен ачыклау мөмкинлеген тудыра.

Ризаэддин Фәхреддин беренчел чыганаклар белән эш иткән тарихчы-тикшеренүче, аның кайсы гына хезмәтен алсаң да, аның хезмәтләренең чыганакчыл базасы киң. Ул чыганакларга зур таләп белән караучы, нык тәфсилле кеше була. Метрика кенәгәләренә тулы ышаныч белән каравы, аның аларга актив рәвештә таянуы – метрика кенәгәләренең тарихи чыганак буларак, нигездә, ышанычлы документ булуы хакында сөйли. Әлбәттә документларны тутыручы аерым имам, муллаларның җаваплык дәрәҗәсе түбән булып, метрика язмаларында ялгышлыклар да булган, Диния нәзарәтенә бу фактлар белән бәйле шикаятьләр дә күп килгән (Гарипова 2014: 14–34). Әлбәттә Риза казый боларның барысы белән дә таныш булган, әмма ул метрика язмаларын ялгыш, ышанычсыз чыганак итеп санамаган. Ул ялгышлыклар социаль тормышта конкрет очраклар өчен, бәлки мөһим дә булганнардыр, әмма тарихны өйрәнү, җәмгыятьне гомумән күзаллау өчен аерым очраклар гына чыганак базасына зур зыян сала алмый.

Ризаэддин Фәхреддиннең дөньяга килү датасы белән, аның рәсми документка – метрика кенәгәсенә теркәлү вакыты арасында да берничә көн бар. Ул үзенең тәрҗемәи хәлендә «1275/1858 ел, 7 җөмадиел-ахирә/31 декабрьдә чәршәмбе көн таң атканда бу михнәт вә мәшакать йорты булган дөньяга килгәнмен. Тугач бишенче көнемдә 1859 ел метрикәсенә 4 гыйнвар вә 3 нче номер белән язылганмын», дип яза (Фәхреддин 1999: 9). Туган көнне төгәл күрсәтү тиеш икәнлеге мәгълүм булса да, ул заманда, хәзерге кануннар таләп иткән дәрәҗәдә, туган көнне шул көн белән язу ул кадәр үк катгый куелмаган. Шулай да, Диния нәзарәте үз матбугат чарасы аша бу хакта имамнарга искәртеп торган. Метрика язмасына төгәл көн белән теркәлмәү шактый четерекле хәлләр дә китереп чыгарырга мөмкин булган. Мисал өчен, аерылу белән яңа никахка керү вакытындагы төгәлсезлекләр кайбер аңлашылмаучанлык та китереп чыгарган, моннан кала, вафат датасы мирас мәсьәләләрен караганда катгый төгәллек таләп итә. Метрика язмасына теркәү кичектерелеп тору төрле сәбәпләр аркасында булу мөмкин. Гадәт буенча, баланы теркәтү ата вазыйфасы, ниндидер сәбәпләр аркасында, моны атасы эшли алмый икән, бу вазыйфаны бабасы үз өстенә алган. Ата кешенең солдатта калуы, я сугышта булуы да, я булмаса, сату-алу эшләре белән йөреп өйдә булмавы да ихтимал. Тагын бер сәбәп – ул балага исем кушу белән, бала туу хөрмәтенә оештырыла торган мәҗлес, бу мәҗлесне оештырганда гына баланы муллага әйтеп метрикага яздыру очраклары да бик еш булган. Шулай итеп, баланы теркәү кичектерелеп торган. Р. Фәхреддиннең тәрҗемәи хәлендә дә чагыла: «Бу вакытта атам сәфәрдә булганга, аннан кайтканнан соң исем биреп, мин туганга кадәр вафат булган углы Ризаэтддин исеме белән атаганнар» (Фәхреддин 1999: 9). Метрика язмаларын комплекслы өйрәнгәндә вафат булган туганның исемен яңа туган балага кушу гадәте татарларда бик еш булмаса да, ул кулланылганы күренә. Гомер итеп вафат булган туганның исеме түгел, ә кече яшьтә сабый вакытта ук вафат булган туганының исеме кую гадәти хәл саналган. Бу традиция үзенә күрә рәсми документларда бу ике сабыйны

бутауга да китергән очраклар булган, бу әлбәттә, бик сирәк күзәтелгән аерым вакыйгалар гына. Шулай ук, әйтеп китәргә кирәк, татарларда бер нәселдә, нәселнең якын буыннары арасында бертөрле исемнәр кабатланмаган. Р. Фәхреддин белән Нурҗәмал абыстайның уллары Хәсән (1897–1899) вафатыннан соң, туган икенче балага Хәсән (1901–1902) исеме бирәләр (Фәхреддин 1999: 31–32). Метрикаларны күпләп өйрәнү тәҗрибәсе яңа туган баланың аңа кадәр туып вафат булган туганының исемен алганнарның гомере озын булмаганлыгын күрсәтә, тик бу һәрберсе дә шулай булган дигән сүз түгел, әмма күпчелегендә бу хәл күренә. Шулай булса да, татарлар традиция буларак моннан баш тартмаганнар.

Ризаэддин Фәхреддин тормышындагы башка вакыйгаларны да метрикада теркәлгән рәвештә сурәтли. Мисал өчен, Минзәлә өязе Чубытлы авылында ахун Габденнасыйр Төхвәтулла улының кызы Нурҗәмал абыстай белән никахлашу вакыйгасы Чубытлы авылы метрикасына 10 июньдә 5 сан астында язылган (Фәхреддин 1999: 31). Ул улларының кайсы авыл метрика кенәгәсенә, нинди көнне, кайсы сан белән язылганын тәрҗемәи хәлендә бик тәфсилле итеп күрсәтә, чөнки биоблиографик хезмәтләр авторы һәр фактның, ул кечкенә генә булса да, зур әһәмияткә ия булуын, фактны табу өчен күп чыганак тикшерергә туры килгәнен бик яхшы аңлый. Төрле җирдә эшләгән-яшәгән Ризаэддин Фәхреддин гаиләсенең тарихы өчен бу гаять мөһим нәрсә, чөнки бала кайда туа, шул мәхәллә метрикасына язылган: Габрахман Кичүчатта, Габделәхәд Илбәктә, Габдерәшид Чубытлы авылында, Зәйнәп, Сәгыйдь, Хәсән Уфа шәһәрендә теркәлгәннәр. Габдрахманны Нурҗәмал абыстай үз туган авылы Чубытлыда тудыра, әмма ул 1887 елда Кичүчат авылы метрикасына теркәлгәнлеге хакында яза Риза казый. Ул моның ник болай эшләнүен аңлата да:

> «... беркадәр игътибарсызлык белән атабыз Кичүчат авылының 114 номерлы метрикәсенә 2 нче номер белән 15 гыйнвар тарихы илә язган. Бу исә вакытында метрикәгә язмыйча, һәр төрле кәгазьләрдә булган эшләрне ел ахырында күчереп, метрикәгә язу җәһәтеннән килеп чыккан», (Фәхреддин 1999: 31–32) ди.

Әлбәттә, имамнарның, муллаларның метриканы ел дәвамында тутырып бармыйча, аерым кәгазьләргә язып барган язмаларын җыеп ел ахырында гына метрика тутыру очраклары еш булган. Р. Фәхреддин этисенең бу эшен шулай аңлатса да, моңа бераз киңрәк карарга кирәк. Татар кешесе нинди дер сәбәпләр аркасында башка авылларда, шәһәрдә яшәсә дә, баласын үз туган авылына, ягъни үзе теркәлгән авыл мәхәлләсе метрика кенәгәсенә яздырган. Фәхреддин хәзрәтнең беренче онытын үз авылы мәхәллә документына язуы табигый, хәтта дөрес тә. Кешенең үз туган җире белән арасы ераклашу, авылыннан күп еллар аерылып башка җирдә яшәгән очракта, баласын үзе яшәгән мәхәллә метрикасына яздыру да табигый хәл итеп кабул ителгән.

Р. Фәхреддиннең тәрҗемәи хәлендә метрика белән бәйле булган тагын бер фактны аерым карап китү кирәк, чөнки бу хәл хәзерге вакытта кайбер урынсыз бәхәсләргә, ялгышлыкларга да китерә башлады. Ризаэддин Фәхреддиннең Кичүчат метрикасында тууын теркәгән документта аның этисе башкорт Фәхреддин дип язылган (ГА РТ 17 кгз). Диния нәзарәтенең метрика язу тәртипләре, аның кагыйдәләре турында аның матбугат чарасы *«Мәгълүматы мәхкәмәи шәргыяи-Оренбургия»* журналы аша бу хакта имамнарга да, җәмәгатьчелеккә дә җиткерелә. Диния нәзарәте баланың исеме янында аның этисенең социаль катлавын түбәндәге очракларда гына күрсәтүне таләп итә: я ул мещан, я дворян, я почетный гражданин булса гына (Имамлык вә метрика 1916: 16–21), ләкин метрика язмаларыннан күренгәнчә, муллалар башка катлауларны да теркәп барганнар, гәрчә бу мәҗбүри булмаса да. Мәсәлән, крестьян яисә зирагатьче, имам, старшина, мөәззин, башкорт, типтәр һ.б. очрый. Югарыда әйткәннәрдән аңлашылганча, метрика язмаларына муллалар тарафыннан кешенең бары тик шөгыле, катламы язылган, метрика язмаларында беркайчан да милләт дигән нәрсә язылмаган, бу чор өчен милләт дигән төшенчә кулланылмаган да. Нәсел чыгышы белән Зөя өязе Шырдан авылыннан (хәзерге Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылы) булган бабасы Юлдаш бине Ишкәй Кичү елгасы буена килеп төпләнеп яши башлый, авыл нигезләнә (Фәхреддин 2006: 62). XVIII гасырда булган халык исәбен алу халыкның катламы, шөгыле нигезендә барган, дәүләт өчен бу мөһим, бу салым салу белән бәйле, яшәгән кешеләрнең нинди халыкка каравы гомумән игътибарда булмый. Ризаэддин Фәхреддиннең бабалары яшәгән як халкы «башкорт» дигән сословиягә карый. Әлбәттә башкорт сословиясендә булган атасы Фәхреддин метрикага үз сословиясе – башкорт дип куелган. Метрикада язылган сословияне хәзерге вакытта милләт итеп күрсәтергә тырышуның бер нигезе юклыгы көн кебек ачык һәм бу бары тик тарихи белемсезлек билгесе генә. Метрикага сылтама белән бу хакта ялгыш фикерләр әйтү, әлбәттә метрика кенәгәләрен комплекслы рәвештә тарихи чыганак буларак фәнни өйрәнелмәүдән килә. Аларның аерым фактларын, аерым кисәкләрен алып аерым кешеләрнең үз файдасына гына куллануы шуңа китерә дә. Метрика язмаларына мөрәҗәгать итүчеләрнең, кызганычка каршы, зур күпчелеге тарихи белеме булмаган кешеләр. Алар бу документтан аерым төбәк, аерым нәселгә караган фактларны чүпләү белән генә шөгыльләнәләр. Шул тар чыганак базасы белән зур фикер әйтергә тырышу да бар, кызганыч, ул фикерләрнең күп очракта тарихи нигезе дә юк.

Метрика язмалары халыкның бер гасырлык тормыш-көнкүрешен күзалларга мөмкинлек бирәләр, аларда халыкның күпгасырлык традициясе, тел үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, тарихы. Алар халык өчен кадерле булган уникаль документлар, татар теленең төрле диалекталь үзенчәлекләре белән язылган бердән-бер зур чыганак базасы. Ризаэддин Фәхреддиннең бу төр чыганакларга мөрәҗәгать итүе һәм зур игътибар бирүе ул юктан гына

түгел, тарихи чыганакларга таләпчән булган галим иң беренче булып бу чыганакларның мөмкинлегеннән файдаланган, аларны саклау шартларын булдырган, өйрәнүнең юнәлешләрен күрсәткән галим. Бай комплекслы чыганакларны һәрьяклап өйрәнү, аларны куллану фәнни проблема, ул кыска вакыт аралыгында гына хәл ителә торган да түгел. Метрика язмалары тарихчылар, телчеләр, дин белгечләре, хәтта медицина тарихы өчен дә кыйммәтле чыганак була ала. Метрика кенәгәләре аерым тикшерү объекты буларак өйрәнелүгә инде күптән мохтаҗ.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

ГА РТ – Государственный архив Республики Татарстан. Ф. 204. Оп. 7 доп. Д. 1.

Имамлык вә метрика 1916 – Имамлык вә метрика язу эше // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыя-и Оренбургия. 1916. № 11. Б.16–21.

Фәхреддин 2006 – Фәхреддин Р. Асар 1 том. Казан: Рухият, 2006.

Фәхреддин 1999 – Фәхреддин Р. Фәнни-биографик җыентык. Казан: Рухият, 1999.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Азаматов Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в в конце XVIII–XIX вв. Уфа: Академия наук Республики Башкортостан, Уфимский научный центр Институт истории, языка и литературы, 1996.

Байбулатова Л.Ф. Источниковая база биоблиографического свода «Асар» Р. Фахреддина. Автореферат дис. ... канд. ист. наук. Казань, 2004.

Гарипова Р.Р. Ведение актов гражданского состояния – метрических книг Волго-Уральских мусульман // Мусульманские духовные лица в социальном и духовном развитии татарского народа. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2014. С. 14–34.

Кутушев Р.Р. Мусульманские метрические книги в Центральном государственном архиве Республики Башкортостан // Отечественные архивы. 2012. № 4. С. 54–59.

Усманова Д.М. Механизм реализации норм мусульманского права в Российской империи к вопросу о метрикации мусульманского населения Волго-Уральского региона на рубеже XIX–XX вв. // Ислам и право в России: Материалы научно-практического семинара «Мусульманское право в мире и России (Северный Кавказ, Поволжье)». Вып. II / Сост. и ред. И.Л. Бабич, Л.Т. Соловьева. М.: РУДН, 2004. С. 40–53.

**Автор турында белешмә:** Сәлахова Эльмира Кадим кызы – тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының ТР халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); ilsalah@mail.ru

*Сәлахова Э.К.* Ризаэддин Фәхреддиннең фәнни-тикшеренү эшләрендә мөһим тарихи чыганак буларак метрика кенәгәләре

*Редакциягә керде 21.04.2020* *Басылуга кабул ителде 02.11.2020*
*Басылды 25.11.2020*

# METRICAL BOOKS AS ONE THE MOST CRITICAL IMPORTANT HISTORICAL SOURCE IN THE SCHOLARLY RESEARCH OF RIZAEDDIN FAKHREDDIN

***E.K. Salakhova***

*Sh.Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*ilsalah@mail.ru*

Metric books are one of the essential sets of sources that provide valuable material for historical research. Unfortunately, metric books' level of use and involvement as historical sources in scientific and scholarly works is still mediocre. At the beginning of the XX century, Rizaeddin Fakhreddin paid attention to those primary sources: he actively referenced them in his scientific research and contributed to their preservation. Thanks to Qadi, the mufti of the USSR Rizaeddin Fakhreddin, the extensive collections of Muslim metric books were preserved.

The key sources for his famous works as «Famous Men», «Famous Women», *«Asar»* were metrical books. It is worth highlighting the bibliographic work, «Asar» There Fakhreddin restored the biography, exact dates of birth and death, and lineage of prominent people, theologians, and imams based on the materials from metrical books.

This article aims to demonstrate the role and importance of metric books in the scientific research of Fakhreddin. This article set several tasks, namely: to analyze material the metric books as sources of historical research, demonstrate the degree of usage of metric books by Fakhreddin in his works, and to evaluate the possibilities of studying these documents in the disclosure of several scholarly topics. For the first time in this publication, the scientific legacy of Fakhreddin is studied from that perspective. The author also draws attention to the fact that the biography of R. Fakhreddin, written by his hand, contains many extracts from the metrical books of his family members and close relatives.

It worth mentioning that the author in his article draws attention to such discussions, which have recently become quite relevant, for example, the question of whether a person registered in the metric books belongs to a particular nationality. As the article will demonstrate below, a person's social affiliation in metric books cannot be interpreted as his nationality. According to the rules of registration of metric books, there was no indication specifying a person's nationality; besides, a person's nationality did not have any significance.

Fakhreddin's reverential attitude and appeal to metric books emphasize their essential place in Tatar-written sources' complex. The scientific study of a voluminous complex of metric books as valuable historical sources should be an important research area in historical science.

**Keywords:** Rizaeddin Fakhreddin, metric books, Tatar historical sources, Spiritual Assembly of Muslims, Tatar scientists, history of the Tatar people, early 20 century

**For citation:** Salakhova E.K. Rizaeddin Fäkhreddinneñ fänni-tiksherenü eshlärendä möhim tarikhi chyganak bularak metrika kenägäläre [Metrical Books as one the Most Critical Important Historical Source in the Scholarly Research of Rizaeddin Fakhreddin]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2020, vol. 5, no. 2, pp. 318–330. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.318-330

REFERENCES

Azamatov D.D. *Orenburgskoye magometanskoye dukhovnoye sobraniye v kontse XVIII–XIX vv.* [Orenburg Mohammedan Religious Assembly at the end of the $18^{th}$–$19^{th}$ centuries]. Ufa: the Republic of Bashkortostan Academy of Sciences Ufa Research Center of the Institute of History, Language and Literature, 1996. (In Russian)

Baybulatova L.F. *Istochnikovaya baza biobibliograficheskogo svoda «Asar» R. Fakhreddina. Avtoref. diss. kand. ist. nauk* [The Source Base of the Biobliographic Arch «Asar» by R. Fakhreddin. Abstract of Cand. Sc. History Diss.]. Kazan, 2004. (In Russian)

Garipova R.R. Vedeniye aktov grazhdanskogo sostoyaniya – metricheskikh knig Volgo-Uralskikh musul'man [Maintaining Civil Status Records – Metrical Books of the Volga-Ural Muslims], *Musul'manskiye dukhovnyye litsa v sotsial'nom i dukhovnom razvitii tatarskogo naroda*. Kazan, Sh. Marjani Institute of History, RT Academy of Sciences, 2014, pp. 14–34. (In Russian)

Kutushev R.R. Musulmanskiye metricheskiye knigi v Tsentral'nom gosudarstvennom arkhive Respubliki Bashkortostan [Muslim Parish Metric Books in the Central State Archive of the Republic of Bashkortostan.]. *Otechestvennyye arkhivy,* 2012, no. 4, pp. 54–59. (In Russian)

Usmanova D.M. Mekhanizm realizatsii norm musul'manskogo prava v Rossiyskoy imperii k voprosu o metrikatsii musul'manskogo naseleniya Volgo-Ural'skogo regiona na rubezhe XIX–XX vv. [The Mechanism of Realisation of Islamic Law Statutes in the Russian Empire on the Issue of the Muslim Population Metrical Registration of the Volga-Ural Region in the $19^{th}$–$20^{th}$ centuries]. *Islam i pravo v mire i Rossii: Materialy nauchno-prakticheskogo seminara «Musulmanskoye pravo v mire i Rossii (Severnyy Kavkaz, Povolzh'e)»*. Moscow: RUDN Publ., 2004, issue 2, pp. 40–53. (In Russian)

**About the author:** Elmira K. Salakhova is a Cand. Sc. (History), Senior Research Fellow of the Department of History and Cultural Heritage of the Peoples of Tatarstan, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); ilsalah@mail.ru

*Received April 21, 2020* *Accepted for publication November 02, 2020*
*Published November 25, 2020*

*Сәлахова Э.К.* Ризаэддин Фәхреддиннең фәнни-тикшеренү эшләрендә мөһим тарихи чыганак буларак метрика кенәгәләре

# МЕТРИЧЕСКИЕ КНИГИ КАК ВАЖНЕЙШИЙ ИСТОРИЧЕСКИЙ ИСТОЧНИК В НАУЧНЫХ ИССЛЕДОВАНИЯХ РИЗАЭДДИНА ФАХРЕДДИНА

***Э.К. Салахова***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*ilsalah@mail.ru*

Метрические книги – один из важнейших источников, содержащих ценный материал для исторических исследований. К сожалению, до настоящего времени уровень разработанности метрических книг как исторических источников оставляет желать лучшего. В начале XX века к метрическим книгам обращался Ризаэддин Фахреддин, который не только активно использовал их в научных исследованиях, но также участвовал в их сохранении. Если на сегодняшний день сохранились большие фонды мусульманских метрических книг, это, безусловно, заслуга кадия, муфтия СССР Ризаэддина Фахреддина.

Основными источниками информации для известных его трудов «Знаменитые мужчины», «Знаменитые женщины», *«Асар»* стали метрические книги. Стоит особо выделить биобиблиографический труд *«Асар»*, где на основе материалов метрических книг Фахреддин сумел восстановить биографию, точные даты рождения и смерти и родословную видных людей, ученых и имамов.

В данной статье предлагается проанализировать роль метрических книг в научных исследованиях Фахреддина. Для достижения поставленной цели ставится несколько задач, а именно: дается аналитический материал о метрических книгах как об источниках научных исследований, рассматривается степень использования метрических книг ученым-исследователем Фахреддином в своих работах, а также говорится об источниковедческих возможностях этих документов в раскрытии целого ряда научных тем. В представленной публикации научное наследие Фахреддина впервые изучается в таком ракурсе. Автор обращает внимание на автобиографию Фахреддина, в которой содержится много выписок из метрических книг членов его семьи и близких родственников.

Следует также отметить, что метрические книги служат источником информации о национальной принадлежности человека; эта тема сегодня активно обсуждается и не теряет своей актуальности. По мнению автора статьи, указанная в метрических книгах социальная принадлежность человека не может расцениваться как информация о его национальности. Автор убежден, что, по правилам оформления метрических книг, не было предусмотрено указание в них национальности человека; кроме того, в данных документах национальность не имела никакого значения.

Фахреддин – ученый-источниковед, чье трепетное отношение к метрическим книгам подчеркивает их важное место в комплексе татарских письменных источников. Научное изучение объемного комплекса метрических книг как ценных исторических источников должно быть важным научно-исследовательским направлением в исторической науке.

**Ключевые слова:** Ризаэддин Фахреддин, метрические книги, татарские исторические источники, архивные документы, Духовное собрание мусульман, татарские ученые, история татар, начало XX века

**Для цитирования:** Салахова Э.К. Ризаэддин Фәхреддиннең фәнни-тикшеренү эшләрендә мөһим тарихи чыганак буларак метрика кенәгәләре // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 318–330. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.318-330

**Сведения об авторе:** Салахова Эльмира Кадимовна – кандидат исторических наук, старший научный сотрудник отдела историко-культурного наследия народов РТ Института истории им. Ш.Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); ilsalah@mail.ru

*Поступила 21.04.2020* *Принята к публикации 02.11.2020*
*Опубликована 25.11.2020*